Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына
һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына
үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 1 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

2004 елның 29 маендагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2010, 21 июль) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $22^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$22^1$ статья. **Татарстан Республикасының Резерв фонды**

1. Татарстан Республикасы бюджетының чыгым өлеше составында Татарстан Республикасының Резерв фондын төзү каралырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасының Резерв фонды Татарстан Республикасы бюджетының максатчан характерга ия булмаган үз керемнәре һәм Татарстан

Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән төзелергә мөмкин.

3. Резерв фонды күләме чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре җитәрлек булмаган очракта Татарстан Республикасының Резерв фонды акчалары тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итү өчен файдаланыла. Татарстан Республикасының Резерв фонды акчалары беренче чиратта Татарстан Республикасының түбәндәге чыгым йөкләмәләрен үтәүгә юнәлдерелә:

1) Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүгә;

2) җирле бюджетларга субвенцияләр бирүгә;

3) Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүгә бәйле чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен җирле бюджетларга субсидияләр бирүгә;

4) гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә.

5. Татарстан Республикасының Резерв фонды акчаларыннан файдалану турында карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә.

6. Татарстан Республикасының Резерв фонды акчаларыннан файдалану Татарстан Республикасы бюджетын үтәү өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

7. Татарстан Республикасының Резерв фонды акчалары Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә банк депозитларында урнаштырылырга мөмкин.

8. Татарстан Республикасының Резерв фонды акчаларыннан файдалану турында мәгълүмат Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы хисап составында законнар нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Хисап палатасына тапшырыла.»;

2) $97^3$ статьяның 4 пунктындагы икенче абзацында «белешмәләре нигезендә» сүзләрен «белешмәләрен исәпкә алып» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 5 июлендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Ватаным Татарстан, 2010, 21 июль) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «10» һәм «12» саннарын «16» һәм «18» саннарына алмаштырырга;

2) икенче абзацта «10» һәм «11» саннарын «16» һәм «17» саннарына алмаштырырга.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 17 статьясындагы 2 пунктының, 18 статьясындагы 2 пунктының, $53^1$ статьясындагы 2 пунктының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 - 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 - 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2010, 21 июль) гамәлдә булуын 2011 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 13 декабре
№ 86 - ТРЗ